**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

«08» февраля 2023 ел № 19-р

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында “Гаилә тарихында гасырлар кайтавазы – тарихта без эзлебез” шәҗәрә фестиваленең муниципаль этабын уздыру турында**

Татарстан Республикасы дәүләт комитетының 17.01.2023 елның 3–од номерлы боерыгы белән расланган "Гаилә тарихында гасырлар кайтавазы-тарихта без эзлебез" шәҗәрә фестивален уздыру турындагы нигезләмәне үтәү йөзеннән, милли гореф-гадәтләр бергәлеге нигезендә гаилә һәм гаилә-туганлык бәйләнешләрен ныгыту, үзенең нәселен өйрәнү, халкын, туган якны өйрәнү, гаилә иҗатына ярдәм итү һәм үстерү, үсеп килүче буынны эстетик, әхлакый һәм рухи яктан тәрбияләүдә аның ролен көчәйтү максатларында:

1. Татарстан Республикасы, Әгерҗе шәһәре, К. Маркс урамы, 10 йорт адресы буенча 2023 елның 6 февраленнән 20 февраленә кадәрге чорда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында “Гаилә тарихында гасырлар кайтавазы - тарихта без эзлебез” шәҗәрә фестиваленең (алга таба - Фестиваль) муниципаль этабын оештырырга һәм үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында “Гаилә тарихында гасырлар кайтавазы – тарихта без эзлебез” шәҗәрә фестиваленең муниципаль этабын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составын расларга(бирелә).

3. Әлеге күрсәтмәнең 2 пунктында күрсәтелгән оештыру комитетына һәм фестивальдә катнашучыларга, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында «Гаилә тарихында гасырлар кайтавазы – тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестиваленең муниципаль этабын уздыру эшен оештыру максатларында, Татарстан Республикасы дәүләт комитетының 17.01.2023 елның № 3-од номерлы боерыгы белән расланган “Гаилә тарихында гасырлар кайтавазы – эзлебезсез тарихта” шәҗәрә фестивален уздыру турындагы нигезләмәгә таянып эш итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт комитетының 17.01.2023 елның 3–од номерлы боерыгы белән һәм фестивальнең муниципаль этабын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетына расланган “Гаилә тарихында гасырлар кайтавазы-тарихта без эзлебез” шәҗәрә фестивален ел саен уздыру турында нигезләмә нигезендә (Yazgulem.Gimazetdino@tatar.ru, 8 (85551)2-17-43), 2023 елның 25 гыйнварыннан 10 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Архив эше буенча Дәүләт комитетына фестивальдә катнашучылар тарафыннан гаризалар бирүне тәэмин итәргә (Alina. Galiymzianova@tatar.ru, 8(843)222-95-66).

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында “Гаилә тарихында гасырлар кайтавазы - Тарихта без эзлебез” шәҗәрә фестиваленең муниципаль этабын уздыру датасын - 2023 елның 20 февралендә билгеләргә.

6. Әлеге күрсәтмәне “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru).

7. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы Э. Н. Бонькинга йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы** **Л.Ф. Нургаянов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 08.02.2023 № 19-р
күрсәтмәсе белән расланды

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында
“Гаилә тарихында Гасырлар кайтавазы – тарихта без эзлебез”
шәҗәрә фестиваленең муниципаль этабын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру
комитеты составы

| | |
|---|---|
| Бонькина Эльмира Нургалиевна | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы – оештыру комитеты рәисе |
| Ершова Любовь Валерьевна | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль үсеш бүлеге җитәкчесе – оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Гыймазетдинова Язгөлем Зәкиевна | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль үсеш бүлеге баш белгече – оештыру комитеты секретаре |
| Оештыру комитеты әгъзалары | |
| Романова Марина Николаевна | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге башлыгы |
| Гайфуллина Гөльнара Марселевна | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты ГХАТ бүлеге җитәкчесе |
| Сафиуллина Вәсилә Гарафутдиновна | “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе” МКУ башлыгы |
| Джаметова Гөльнас Фелисовна | “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының тарих һәм мәдәни мирасы музее” МБМУ директоры |
| Абзалиева Дания Зангировна | «ТАТМЕДИА» АҖ филиалының Әгерҗе районы «Әгерҗе хәбәрләре» («Агрызские вести») газетасының баш мөхәррир-җитәкчесе (килешү буенча) |